Аңлатма язуы

3 нче сыйныф укучылары өчен татар теленнән тематик тест биремнәре исем һәм сыйфат сүз төркемнәрен ныгыту һәм укучыларның шушы темаларны үзләштерү дәрәҗәсен ачыклау максатынан төзелде.

Тест биремнәре ике вариантта тәкъдим ителә, дәресләрдә өйрәнгән барлык темаларны үз эченә ала. Тест укучылар өчен гомуми инструкция бирү белән башлана. Интсрукциядә кыска һәм төгәл итеп нәрсә эшләргә кирәклеге аңлатыла.

**3 нче сыйныф укучылары өчен татар теленнән тематик тест биремнәре**

Төзеде: Сарварова Фирая Мөбәрәк кызы, башлангыч сыйныфлар укытучысы

**Исем сүз төркеме 1 вариант**

*Биремнәрнең һәрберсенә бирелгән 3 җавап вариантының берсен-дөресен генә сайлап ал.*

1. 1.Исем нәрсәне белдерә?

а) предметның билгесен;

ә) предметны;

б) предметның эшен;

2. Исем нинди сорауларга җавап бирә?

а) кем? нәрсә?

ә) нинди? кайсы?

б) нишли? нишләде?

3.Ялгызлык исемне билгелә.

а) ата-ана

ә) Агыйдел

б) башкала

4.Уртаклык исемне билгелә.

а) аккош

ә) Салават

б) Сабантуй

5.Берлек сандагы исемне билгелә.

а) болыннар

ә) балалар

б) көнбагыш

6.Күплек сандагы исемне билгелә.

а) алмагач

ә) малайлар

б) көнбагыш

7.Юнәлеш килешендәге исемне билгелә.

а) сыйныфта

ә) сыйныфны

б) сыйныфка

8.Чыгыш килешендәге исемне билгелә.

а) табигатьтә

ә) табигатьтән

б) табигатьне

9.Күплек сандагы калын әйтелешле иялек килешендәге сүзне тап.

а) наратның

ә) имәннәрне

б) чыршыларның

10.Күплек сандагы нечкә әйтелешле урын-вакыт килешендәге сүзне тап.

а) чәчәктә

ә) гөлләрдә

б) яфраклардан

**3 сыйныф Исем сүз төркеме 2 вариант**

*Биремнәрнең һәрберсенә бирелгән 3 җавап вариантының берсен-дөресен генә сайлап ал.*

1..Исем нәрсәне белдерә?

а) предметны;

ә) предметның билгесен;

б) предметның эшен;

2. Исем нинди сорауларга җавап бирә?

а) нишли? нишләде?

ә) кем? нәрсә?

б) нинди? кайсы?

3.Ялгызлык исемне билгелә.

а) каракош

ә) гөлҗимеш

б) Фирая

4.Уртаклык исемне билгелә.

а) Мәскәү

ә) Сарварова

б) бозваткыч

5.Берлек сандагы исемне билгелә.

а) елгалар

ә) көнбагыш

б) читекләр

6.Күплек сандагы исемне билгелә.

а) карабодай

ә) арпа

б) басулар

7.Юнәлеш килешендәге исемне билгелә.

а) мәктәпне

ә) мәктәпкә

б) мәктәптән

8.Чыгыш килешендәге исемне билгелә.

а) һавада

ә) һаваны

б) һавадан

9.Күплек сандагы калын әйтелешле иялек килешендәге сүзне тап.

а) балыкның

ә) үрдәкләрне

б) балыкларның

10.Күплек сандагы нечкә әйтелешле урын-вакыт килешендәге сүзне тап.

а) чәчәктә

ә) орлыкны

б) чәчәкләрдә

**3 сыйныф Сыйфат сүз төркеме 1 вариант**

*Биремнәрнең һәрберсенә бирелгән 4 җавап вариантының берсен-дөресен генә сайлап ал.*

1.Сыйфат нәрсәне белдерә?

а) предметны;

ә) предметның билгесен;

б) предметның эшен;

в)предметның санын

2. Сыйфат нинди сорауларга җавап бирә?

а) нишли? нишләде?

ә) кем? нәрсә?

б) нинди? кайсы?

в) ничә? ничәнче?

3.Сыйфатларның ничә дәрәҗәсе бар?

а) бер

ә) ике

б) өч

в) дүрт

4.Гади дәрәҗәдәге сыйфатны тап.

а) ямь-яшел

ә) кызгылт

б) караңгы

в) зуррак

5.Чагыштыру дәрәҗәдәге сыйфатны тап.

а) ямь-яшел

ә) кызгылт

б) караңгы

в) зуррак

6.Артыклык дәрәҗәдәге сыйфатны тап.

а) ямь-яшел

ә) кызгылт

б) караңгы

в) зуррак

7.Кимлек дәрәҗәдәге сыйфатны тап.

а) ямь-яшел

ә) кызгылт

б) караңгы

в) зуррак

8. **Зур** сүзенең синонимын тап.

а) кечкенә

ә) олы

б) нәни

в) вак

9.**Тирән** сүзенең антонимын тап.

а) тар

ә) биек

б) сай

в) киң

10.Күчерелмә мәгънәдә кулланылган сыйфатны тап.

а) алтын алка

ә) алтын беләзек

б) алтын кул

в) алтын йөзек

**3 сыйныф Сыйфат сүз төркеме 2 вариант**

*Биремнәрнең һәрберсенә бирелгән 4 җавап вариантының берсен-дөресен генә сайлап ал.*

1.Сыйфат нәрсәне белдерә?

а) предметның эшен;

ә) предметның билгесен;

б) предметны;

в)предметның санын.

2. Сыйфат нинди сорауларга җавап бирә?

а) нишли? нишләде?

ә) нинди? кайсы?

б) кем? нәрсә?

В) ничә? ничәнче?

3.Сыйфатларның ничә дәрәҗәсе бар?

а) бер

ә) өч

б) ике

в) дүрт

4.Гади дәрәҗәдәге сыйфатны тап.

а) саргылт

ә) биегрәк

б) озын

в) кып-кыска

5.Чагыштыру дәрәҗәдәге сыйфатны тап.

а) саргылт

ә) биегрәк

б) озын

в) кып-кыска

6.Артыклык дәрәҗәдәге сыйфатны тап.

а) саргылт

ә) биегрәк

б) озын

в) кып-кыска

7.Кимлек дәрәҗәдәге сыйфатны тап.

а) саргылт

ә) биегрәк

б) озын

в) кып-кыска

8. **Эссе** сүзенең синонимын тап.

а) салкын

ә) җилле

б) кызу

в) кояшлы

9.**Тапкыр** сүзенең антонимын тап.

а) акыллы

ә) уйчан

б) белемле

в) зирәк

10.Күчерелмә мәгънәдә кулланылган  сыйфатны тап.

а) алтын алка

ә) алтын беләзек

б) алтын йөзек

в) алтын йөрәк